ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» марта 2025 ел № 55

«Әгерҗе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларын һәм физик затларны ачыклау һәм легальләштерү ведомствоара комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.11.2020 елның 366 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Штат үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Әгерҗе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларын һәм физик затларны ачыклау һәм легальләштерү ведомствоара комиссиясе турында» 11.11.2020 елның 366 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Әгерҗе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларын һәм физик затларны ачыклау һәм легальләштерү ведомствоара комиссиясе составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 11.11.2020 елның 366 номерлы карары белән расланган Әгерҗе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларын һәм физик затларны ачыклау һәм легальләштерү ведомствоара комиссиягә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.04.2023 елның 103 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәриповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль
районы Башкарма комитетының
04.03.2025 елның 55 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районы территориясендә законсыз эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашыручы хуҗалык субъектларын һәм физик затларны ачыклау һәм легальләштерү ведомствоара комиссиясе**
**СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе | Салихов Илгиз Хәйдәрович |
| 2 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты рәисе урынбасары, җитәкчесе урынбасары | Шәрипов Рөстәм Рәшитович |
| 3 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш бүлеге баш белгече, комиссия секретаре | Биктагирова Диана Сергеевна |
| | Ведомствоара комиссия әгъзалары: | |
| 4 | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 9 нчы номерлы районара инспекциясе башлыгы урынбасары (килешү буенча) | Миннәхмәтов Альберт Зөлфәтович |
| 5 | Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенең начальнигы урынбасары - полиция начальнигы (килешү буенча) | Мөхәммәтҗанов Рифат Рафинатович |
| 6 | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенең Алабуга, Әгерҗе, Менделеевск районнарында (Алабуга ТО) территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча) | Гыйсмәтуллина Раися Тәлгатовна |
| 7 | Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) | Бадахшин Альфред Нәвитович |
| 8 | Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының икътисадый үсеш бүлеге башлыгы | Заитова Аида Салиховна |